**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы әгъзаларын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы әгъзаларын раслау турында» 2017 елның 1 февралендәге ПУ-89 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 сентябрендәге ПУ-833 номерлы һәм 2018 елның 25 гыйнварындагы ПУ-91 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зарипов Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча);»;

б) бишенче абзацта «вазыйфаларын башкаручы» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) унынчы абзацта «Россия фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Е.К. Завойский исемендәге Казан физика-техника институты» сүзләрен «Россия фәннәр академиясе Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең аерымланган структур бүлекчәсе – Е.К. Завойский исемендәге Казан физика-техника институты» сүзләренә алмаштырырга;

г) уникенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

д) унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әюпова Ирада Хафизҗан кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын;».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 19 декабрь
№ ПУ-779